КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 апрель г.Казань № 328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» еллык республика конкурсын гамәлгә кую турында» 2017 ел, 11 май, 274 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» еллык республика конкурсын гамәлгә кую турында» 2017 ел, 11 май, 274 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәдә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Конкурс ел саен түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Эшкәртү лидеры» – ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында җитештерелгән полимер продукция, каучук һәм резина-техник эшләнмәләр җитештерү һәм эшкәртүнең максималь күләмен күрсәткән катнашучылар арасында;

«Үсеш лидеры» – ел нәтиҗәләре буенча полимер продукция, каучук һәм резина-техник эшләнмәләр җитештерү һәм эшкәртүнең иң югары темпларын күрсәткән катнашучылар арасында;

«Инновацияләр лидеры» – инновацион эшләнмәләрне гамәлгә кертү һәм полимер продукция һәм каучук эшкәртү тирәнлеген арттыру, резина-техник эшләнмәләр җитештерү белән шөгыльләнүче катнашучылар арасында.

«Эшкәртү лидеры» һәм «Үсеш лидеры» номинацияләрендә бер җиңүче

билгеләнә. «Инновацияләр лидеры» номинациясендә ике җиңүче билгеләнә.»;

2.1 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инновацияләр лидеры» - әлеге Нигезләмәнең 3, 4 нче кушымталары.»;

1-3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

4 нче кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсының конкурс комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан Р.В. Сикорскийны, А.Ш. Бикмурзинны, Г.С. Дьяконовны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Миңсадыйров Ирек Илдар улын | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының нефть, газ, химия комплексы үсешен координацияләү бүлеге башлыгын, конкурс комиссиясе секретарен |
| Сафин Айрат Фоат улын | «Түбән Кама нефть химиясе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча) |
| Юшко Сергей Владимировичны | «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында «Эшкәртү лидеры» номинациясендә катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме | |
| Юридик затның адресы | |
| Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы) | |
| Тел./факс: | |
| E-mail: | |

Полимер продукция, каучук эшкәртү һәм
резина-техник эшләнмәләр җитештерү турында мәгълүмат
(«Эшкәртү лидеры» номинациясе)

| Чимал маркалары исеме | Үлчәү берәмлеге | Барлыгы эшкәр-телгән | Татарстан Республикасында җитештерелгән чимал | | Татарстан Республикасыннан читтә җитештерелгән чимал | | Импорт | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | хисап елы | киләсе елга план | хисап елы | план на следую-щий год | хисап елы | киләсе елга план |
| 1. Полиэтилен | тонна | | | | | | | |
| 2. Полипропилен | тонна | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

1. Татарстан Республикасыннан читтә сатып алу сәбәпләре турында һәм импорт буенча белешмә.

2. Яңа инвестиция проектын тормышка ашырганда яки эшкәртелә торган полимер материаллар спектрын киңәйткәндә – ирекле формада проект турында белешмә.

Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм. Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза.

Җитәкче ____________ ______________/_____________/

*(вазыйфа)* *(имза)* *Ф.И.А.ис.(булганда)*

М.У. (булганда)

______________________________________

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында «Үсеш лидеры» номинациясендә катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме | |
| Юридик затның адресы | |
| Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы) | |
| Тел./факс: | |
| E-mail: | |

Полимер продукция, каучук эшкәртү һәм резина-техник эшләнмәләр җитештерү турында мәгълүмат («Үсеш лидеры» номинациясе)

| Чимал маркалары исеме | Үлчәү берәмлеге | Эшкәртелгән полимерлар | | | Узган елның хисап елына процент чагыштырмасы | Сәнәгать җитештерүе индексы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | алдагы ел | хисап елы | чираттагы елга план | | |
| 1. Полиэтилен | тонна | | | | | |
| 2. Полипропилен | тонна | | | | | |
| | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | |

Яңа инвестиция проектын тормышка ашырганда яки эшкәртелә торган полимер материаллар спектрын киңәйткәндә, заявкага ирекле формада проект турында белешмә теркәлә.

Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм. Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза.

Җитәкче _____________ ________________/_______________/
*(вазыйфа)* *(имза)* *Ф.И.А.ис.(булганда)*
М.У. (булганда)

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында полимерлар җитештерү һәм эшкәртү өлкәсендә «Инновацияләр лидеры» номинациясендә катнашуга
заявка

| | |
|---|---|
| Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме | |
| Юридик затның адресы | |
| Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы) | |
| Тел./факс: | |
| E-mail: | |

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

1. Техник тасвирлама һәм куллану өлкәсе белән продукт турында белешмә (шундый ук продуктлар белән чагыштырганда конкурентлы өстенлекләре; яңалык дәрәҗәсе; импортны алыштыру программасына туры килү).
2. Инновация продуктын гамәлгә керткәндә килеп чыккан финанс-икътисадый нәтиҗә.
3. Өстәмә материаллар (гариза бирүче ихтыярына).

Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм. Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза.

Җитәкче _____________ _______________/______________/

*(вазыйфа)* *(имза)* *Ф.И.А.ис.(булганда)*

М.У. (булганда)

_______________________________________

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эш-кәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында каучук эшкәртү, резина-техник эшләнмәләр җитештерү өлкәсендә «Инновацияләр лидеры» номинациясендә катнашуга заявка

| | |
|---|---|
| Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме | |
| Юридик затның адресы | |
| Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы) | |
| Тел./факс: | |
| E-mail: | |

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

1. Техник тасвирлама һәм куллану өлкәсе белән продукт турында белешмә (шундый ук продуктлар белән чагыштырганда конкурентлы өстенлекләре; яңалык дәрәҗәсе; импортны алыштыру программасына туры килү).
2. Инновация продуктын гамәлгә керткәндә килеп чыккан финанс-икътисадый нәтиҗә.
3. Өстәмә материаллар (гариза бирүче ихтыярына).

Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм. Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза.

Җитәкче _____________ _______________/______________/
*(вазыйфа)* *(имза)* *Ф.И.А.ис.(булганда)*
М.У. (булганда)

______________________________________